КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 3 июнь г.Казань № 392

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 15 июнь, 452 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 15 июнь, 452 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 26 март, 275 нче, 2022 ел 22 август, 884 нче, 2023 ел, 06 февраль, 106 нчы, 2023 ел, 04 июль, 787 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «2013 – 2025 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасы» сүзләрен «Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» Татарстан Республикасы дәүләт программасы» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктның җиденче абзацында «2023» саннарын «2024» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2023 елда шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга яшь кош-корт сатып алуга чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

исемендә «2023» саннарын «2024» саннарына алмаштырырга;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Тәртип 2024 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга 2024 елның 1 апреленнән 1 июленә кадәр кош-корт (каз, үрдәк, күркә, бройлер чебиләр) сатып алуга тотылган чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр (алга таба - субсидия) бирү механизмын билгели.»;

8 пунктның беренче абзацында «2023» саннарын «2024» саннарына алмаштырырга;

9 пунктта:

икенче абзацта «2023» саннарын «2024» саннарына алмаштырырга;

дүртенче абзацта «2023» саннарын «2024» саннарына алмаштырырга;

12 пунктта «2023» саннарын «2024» саннарына алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин